**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 2 сентябрь № 611

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 18 июль, 611 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1183 нче; 2013 ел, 30 гыйнвар, 48 нче; 2013 ел, 11 май, 313 нче; 2013 ел, 29 июнь, 455 нче; 2014 ел, 10 гыйнвар, 2 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 20 нче; 2014 ел, 28 май, 362 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 25 август, 613 нче; 2014 ел, 6 октябрь, 726 нчы; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 29 декабрь, 1050 нче; 2015 ел, 4 август, 565 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1025 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтада:

9 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «9. | Түбәндәге бүлекләрдә (палаталарда) эшләү: пешкән авыруларны дәвалау; көчле агуланган авыруларны дәвалау; ми кан әйләнеше бозылган авырулар өчен неврология бүлекләрендә (палаталарында); җитлекми туган балаларны дәвалау; үзәк нерв системасы функциясе бозылган пациентларны медицина тернәкләндерүгә; периферия нерв системасы функциясе бозылган пациентларны медицина тернәкләндерүгә; соматик авырулы пациентларны медицина тернәкләндерүгә; амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмасының медицина тернәкләндерүгә бүлекләрендә (палаталарында) | беренче дәрәҗәдәге медицина һәм фармацевтика персоналы | 1 | 25»; |
| | | урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 1, 3 – 5 | |
| | | табиблар һәм провизорлар | 1 – 4 | |
| | | структур бүлекчәләр җитәкчеләре | 1 – 2 | |

11 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «11. | Барлык профильләрдәге эренле авырулар хирургиясе бүлекләрендә (палаталарында) эшләү | беренче дәрәҗәдәге медицина һәм фармацевтика персоналы | 1 | 25»; |
| | | урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 3 – 5 | |
| | | табиблар һәм провизорлар | 1 – 4 | |
| | | структур бүлекчәләр җитәкчеләре | 2 | |

37 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «37. | Дәвалау-профилактикалау медицина оешмалары стационарларының кабул итү бүлекләрендә, кабул итү-диагностикалау бүлекләрендә эшләү | беренче дәрәҗәдәге медицина һәм фармацевтика персоналы | 1 | 15»; |
| | | урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 1– 5 | |
| | | табиблар һәм провизорлар | 1 – 4 | |
| | | структур бүлекчәләр җитәкчеләре | 1 – 2 | |

Нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтада:
9 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «9. | Түбәндәге бүлекләрдә (палаталарда) эшләү: пешкән авыруларны дәвалау; көчле агуланган авыруларны дәвалау; ми кан әйләнеше бозылган авырулар өчен неврология бүлекләрендә (палаталарында); җитлекми туган балаларны дәвалау; үзәк нерв системасы функциясе бозылган пациентларны медицина тернәкләндерүе; периферия нерв системасы функциясе бозылган пациентларны медицина тернәкләндерүе; соматик авырулы пациентларны медицина тернәкләндерүе; амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмасының медицина тернәкләндерүе бүлекләрендә (палаталарында) | 11, 26, 31, 34, 37, 39, 42, 63, 105, 111, 147, 155, 156 | 147»; |

11 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «11. | Барлык профильләрдәге эренле авырулар хирургиясе бүлекләрендә (палаталарында) эшләү | 45, 105»; | |

37 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «37. | Дәвалау-профилактикалау медицина оешмалары стационарларының кабул итү бүлекләрендә, кабул итү-диагностикалау бүлекләрендә эшләү | 65»; | |

Нигезләмәгә теркәлгән 3 нче кушымтада:
65 нче юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «65. | Кабул итү бүлеге (бүлмәсе), кабул итү-диагностикалау бүлеге | 65»; | |

117 нче юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «117. | Паллиатив медицина ярдәме бүлеге | 117 | Ашыгыч медицина ярдәме станцияләре (бүлекләре), ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме станцияләре (бүлекләре), паллиатив медицина ярдәме бүлекләре»; |

147 нче юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «147. | Үзәк нерв системасы функциясе бозылган пациентларны медицина тернәкләндерүгә бүлеге (палатасы) | 147 | Амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмасы – Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең медицина тернәкләндерүгә бүлеге (кабинетлары) |

148 нче юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «148. | Үзәк нерв системасы функциясе бозылган пациентларны медицина тернәкләндерүгә бүлеге (палатасы) | 148 | Амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмасы – Чаллы шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең медицина тернәкләндерүгә бүлеге (кабинетлары) |

Нигезләмәгә теркәлгән 4 нче кушымтада:
13 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «13. | Түбәндәге бүлекләрдә (палаталарда) эшләү: пешкән авыруларны дәвалау; көчле агуланган авыруларны дәвалау; ми кан әйләнеше бозылган авырулар өчен неврология бүлекләрендә (палаталарында); җитлекми туган балаларны дәвалау; үзәк нерв системасы функциясе бозылган пациентларны медицина тернәкләндерүгә; периферия нерв системасы функциясе бозылган пациентларны медицина тернәкләндерүгә; соматик авырулы пациентларны медицина тернәкләндерүгә; амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмасы (хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар өчен) | Сәламәтлек саклау оешмаларында һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыра торган оешмаларда турыдан-туры дәвалау процессында катнашучы өченче дәрәҗәдәге белгечләр вазыйфалары | 1– 2 | 25»; |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | – Чаллы шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең медицина тернәкләндерүгә бүлекләрендә (палаталарында) | | | |

түбәндәге эчтәлекле 20 нче пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «20. | Суд-медицина экспертизасы бюросында эшләү | Сәламәтлек саклау оешмаларында һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыра торган оешмаларда өченче дәрәҗәдәге белгечләр вазыйфалары | 2 | 65»; |

Нигезләмәгә теркәлгән 12 нче кушымтаның 5 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «5. | Медицина хезмәтләре күрсәтү буенча стационар медицина оешмаларында (структур бүлекчәләрендә, көндезге стационарларны кертеп) эшләү | 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9, 10, 11, 12, 13,14, 15, 16, 17, 18, 19, 21, 22, 24, 25, 26, 27, 28, 29, 30, 31, 32, 33, 34, 36, 37, 38, 39, 40, 41, 42, 43, 44, 45, 46, 47, 48, 50, 52, 53, 54, 55, 56, 57, 59, 60, 62, 63, 64, 65, 67, 69, 70, 71, 73, 76, 77, 78, 79, 85, 87, 88, 89, 90, 91, 92, 93, 94, 97, 101, 102, 103, 104, 105, 106, 107, 108, 109, 111, 112, 113, 114, 117, 124, 125, 126, 127, 128, 129, 137, 139, 142, 144, 147, 149, 150, 151, 152, 153, 155, 156»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләрнең гомумтармак эшче профессияләре һәм гомумтармак җитәкчеләр вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 21 – 38 нче пунктлар өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «21. | Аскы (яки өске һәм аскы) очлыклар параличына (парезына) һәм оча органнары функциясе бозылуга китерә торган арка мие зарарлануы белән авыручылар оешмаларында (бүлекләрендә, палата- | эш бүлмәләрен җыештыручы, кастелянша, буфетчы | 25 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ларында) эшләү | | |
| 22. | Түбәндәге бүлекләрдә (палаталарда) эшләү: пешкән авыруларны дәвалау; көчле агуланган авыруларны дәвалау; ми кан әйләнеше бозылган авырулар өчен неврология бүлекләрендә (палаталарында); җитлекми туган балаларны дәвалау; үзәк нерв системасы функциясе бозылган пациентларны медицина тернәкләндерүе; периферия нерв системасы функциясе бозылган пациентларны медицина тернәкләндерүе; соматик авырулы пациентларны медицина тернәкләндерүе; амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмасының медицина тернәкләндерүе бүлекләрендә (палаталарында) | эш бүлмәләрен җыештыручы, кастелянша, буфетчы | 25 |
| 23. | Барлык профильләрдәге эренле авырулар хирургиясе бүлекләрендә (палаталарында) эшләү | эш бүлмәләрен җыештыручы, кастелянша, буфетчы | 25 |
| 24. | Патологоанатомия бюроларында (бүлекләрендә, бүлекчәләрендә), мәет тукымалары, органнары һәм кан әзерләү (консервацияләү) бүлекләрендә эшләү | эш бүлмәләрен җыештыручы, кастелянша | 25 |
| 25. | Анестезиология-реанимация бүлекләрендә (төркемнәрендә); реанимация һәм интенсив дәвалау бүлекләрендә (палаталарында); психоневрология авырулары булганда озак даими карауга мохтаҗ авырулар өчен геронтология бүлекләрендә (палаталарында) эшләү | эш бүлмәләрен җыештыручы, кастелянша, буфетчы | 15 |
| 26. | Хирургия профилендәге бүлекләрдә, палаталарда, кабинетларда; травматология пунктларында эшләү; процедура кабинетлары медицина персоналыннан тыш | эш бүлмәләрен җыештыручы, кастелянша, буфетчы | 15 |
| 27. | Физиотерапевтика бүлекләрендә, минераль су һәм ләм белән дәвалау шифаханәләрендә (бүлекләрендә, кабинетларында) эшләү | эш бүлмәләрен җыештыручы, кастелянша | 15 |
| 28. | Барлык профильләрдәге рентген, радиология һәм рентгенорадиология бүлек- | эш бүлмәләрен җыештыручы, | 15 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ләрендә, бүлекчәләрендә, лабораторияләрендә, төркемнәрендә һәм кабинетларында, ташларны рентген бәрмә дулкын белән дистанцион вату бүлекләрендә (ОРУДДКА), рентгенология тикшеренүләренең контрастлы һәм йөрәк эче ысуллары буенча үзәкләрдә, бүлекләрдә, кабинетларда эшләү | кастелянша, буфетчы | |
| 29. | Химиотерапевтика препаратларының зур дозаларын озак вакыт куллану төп дәвалау ысулы булган медицина оешмалары бүлекчәләрендә (палаталарында), кабинетларында эшләү | эш бүлмәләрен җыештыручы, кастелянша, буфетчы | 15 |
| 30. | Ультратавыш диагностикасы бүлекләрендә (кабинетларында) һәм эндоскопия бүлекләрендә (кабинетларында) эшләү | эш бүлмәләрен җыештыручы, кастелянша | 15 |
| 31. | Кан салу станцияләрендә, кан һәм аның компонентларын әзерләү бүлекләрендә эшләү | эш бүлмәләрен җыештыручы, кастелянша, буфетчы | 15 |
| 32. | Лабораторияләрдә (бүлекләрдә, бүлекчәләрдә) | эш бүлмәләрен җыештыручы, кастелянша | 15 |
| 33. | Үзәкләштерелгән стерилизация һәм автоклав, стоматология оешмаларында бүлекләрендә (кабинетларында), лазер җайланмаларында, фельдшерлык-акушерлык пунктларында эшләү | эш бүлмәләрен җыештыручы, кастелянша | 15 |
| 34. | Медицина оешмаларының процедура кабинетларында, дезинфекция камераларында, эпидемиология төркемнәрендә (бүлекләрендә) эшләү | эш бүлмәләрен җыештыручы | 15 |
| 35. | Онкологик авырулар оешмаларында, бүлекләрендә, палаталарында, кабинетларында; гемобластоз һәм кан ясалу депрессияләре белән авыручылар бүлекләрендә (палаталарында), кабинетларында, хосписларда, авыруларны шәфкать туташлары карый торган йортларда эшләү | эш бүлмәләрен җыештыручы, кастелянша, буфетчы | 15 |
| 36. | Дәвалау-профилактикалау медицина оешмалары стационарларының кабул итү бүлекләрендә, кабул итү-диагностикалау | эш бүлмәләрен җыештыручы | 15 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | бүлекләрендә эшләү | | |
| 37. | Сәламәтлек органнары тарафыннан аларга халыкны ВИЧ-инфекциягә тикшерү һәм СПИД белән авырган һәм ВИЧ-йогышланганнардан алган канны һәм биологик сыеклыкларны тикшерү йөкләнгән медицина оешмалары лабораторияләрендә һәм төркемнәрендә, серология лабораторияләрендә эшләү | эш бүлмәләрен җыештыручы | 80 |
| 38. | Хастаханә кизү торган көннәрдә ашыгыч медицина ярдәме хастаханәләрендә; тәүлек буе кичектергесез хирургия ярдәме күрсәтү бүлекләрендә эшләү | эш бүлмәләрен җыештыручы, кастелянша, буфетчы | 15.». |

2. Бу карарның гамәле 2016 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков